Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлегенең
Ивановка авылы гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 29 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Ивановка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Ивановка авылында Нагорная урамы, Яшьлек урамы, Мәктәп тыкрыгы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;

Ивановка авылында (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Таулы, Энтузиастлар, Чишмә, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту.

II. Җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү:

Ивановка авылы территориясендә үлән чабу;

- бензокос (триммер) сатып алу.

III. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу;

янгын сүндерү җиһазлары һәм янгын сүндерү инвентары сатып алу;

янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 350 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 178.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар «РИЗА»позициясе өчен бертавыштан тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге составына керүче Ивановка авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Ивановка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Ивановка авылында Нагорная урамы, Яшьлек урамы, Мәктәп тыкрыгы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау;

Ивановка авылында (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Таулы, Энтузиастлар, Чишмә, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту.

II. Җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү:

Ивановка авылы территориясендә үлән чабу;

- бензокос (триммер) сатып алу.

III. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу;

янгын сүндерү җиһазлары һәм янгын сүндерү инвентары сатып алу;

янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

сораулары буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иванов ка авылы, Яшьлек урамы, 5, Ивановка авылы, Колхоз урамы, 16Б, Ивановка авылы, Дорожная урамы, 32, Михайловка авылы, Центральная урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.П.Бодряева